

Быел Мордовия Республикасы Главасы Артём Здунов тарафыннан сәламәтлек елы дип игълан ителде. Соңгы елларда Торбеево районы сәламәтлек саклау олкәсендә житди vзгәрешләр булган һәм Торбеево vзәк район хастаханәсе баш табибы, Мордовиядә хормәт казанган Айсылу Мяхмут кызы СЕМОЧКИНА әлеге олкәдәге яналыклар белән таныштырды. Айсылу Мяхмут кызы аралашканда болай дип сойләде:

- Безнен очен халык сәламәтле-ге - топ остенлек. Торбеево районы сәламәтлек саклау системасы шу-на юнәлтелгән. Район хастаханәсе структурасына тәvлек буе эшли торган 54 койкалы стационар керә, шул исәптән терапия бvлегендә - 28 койка, гинекология бvлегендә - 1 койка, йогышлы авырулар бvлегендә - 7, педиатрия бvлегендә - 3, травматология бvлегендә - 2,  хирургия бvлегендә - 3, паллиатив бvлектә - 10 койка бар. Шулай ук район халкы кондезге стационарда сәламәтлеген яхшырта ала: анда 47 койка-урын урнашкан.

Поликлиникабыз 450 кешелек ол-кәннәр һәм балалар сменасына исәпләнгән. Авыл кешеләре беренчел ярдәмне бер фельдшер-акушерлык һәм 21 фельдшерлык пунктларында алалар. Хастаханә районда яшәvче 18099 кешегә хезмәт кvрсәтә, шулардан эшкә яраклы 11065 кеше, пенсия яшендәге 4447 кеше, 3137 бала.

Янартылган поликлиникада 16 белгечлек буенча кабул итv оештырылды һәм алып барыла: терапия, гомуми табиб практикасы, акушерлык-гинекология, неврология, эндокринология, отоларингология, офтальмология, педиатрия, психиатрия, наркология, дерматовенерология, фтизиатрия, хирургия, онкология, функциональ диагностика, стоматология. Диагностика хезмәтен клиник - диагностика лабораториясе, рентгенология хезмәте, утратавыш диагностикасы кабинеты, физиотерапия хезмәте, эндоскопия кабинеты һәм функциональ диагностика кабинеты бар.

Узган ел гына да поликлиника бvлегендә 142170 кеше vтте. 2025 елда «Сәламәтлек саклаунын беренчел звеносын модернизацияләv» милли проекты кысаларында поликлиниканын дvрт катлы бинасына 93 миллион 762 мен сумлык капиталь ремонт ясалды. Сигез миллион сумлык медицина жиһазлары сатып алынды.

Хезмәткәрләребезгә килгәндә, район vзәк хастаханәсенен Торбеево бvлекчәсендә 237 кеше эшли, шулардан - 41 табиб, 123 урта медицина персоналы, 73 башка хезмәткәр. Амбулатор шартларда табиблар - 95,3%, урта медицина персоналы - 99,4% тәшкил итә. Шулай, бездә 3 педиатрия, 6 терапия участоклары, гомуми практика табибларынын бер участогы эшли, алар 100% медицина персоналы белән комплектланган. Носакино авылынын бер фельдшерлык пунктында гына вакантлы урын бар. Персоналны

комплектлауда да торле проектлар ярдәмгә килә. Мәсәлән, 2025 елда штатларны тулыландыру максатында «Сәламәтлек саклауны vстерv» проектын гамәлгә ашыры торган «Земство докторы/Земство фельдшеры» программасы буенча Морд-Юнки ФАПына бер табиб-анестезиолог-реаниматолог, фельдшерлык пункты модире, шәфкать туташы эшкә урнаштырылды.

Сонгы елларда дәvләт медицина хезмәткәрләренен керемнәрен арттыруга зур игътибар бирә. Әйтик, 2025 елда «Торбеево vзәк район хастаханәсе» буенча югары медицина, фармацевтика яки башка югары белемле табиблар һәм хезмәткәрләрнен уртача айлык хезмәт хакы – 75567 сум, урта медицина персоналынын - 36290 сум тәшкил иткән. Гомумән учреждение буенча - 40080 сум.

Мордовия Республикасы Главасы Артём Здунов игълан иткән сәламәтлек елында торле проектлар остендә актив эшләвебезне дәвам итәбез. «Дәвамлы һәм актив тормыш» милли проекты кысаларында (2026-2027 елларда), Дракино һәм Жуково авылларында блок-модульле фельдшерлык пунктлары тозv планлаштырыла. «Гаилә» милли проектын гамәлгә ашыру кысаларында репродуктив система авыруларын иртәрәк ачыклау һәм халыкнын репродуктив сәламәтлеген саклау медицина оешмасы эшенен ин моһим юнәлешләреннән берсе булып тора. Ел саен 15-17 яшьлек vсмерләргә репродуктив сәламәтлек ягыннан профилактик тикшерv vткәрәбез. 2025 елда 503 яшvсмер медицина тикшерелvе vтте; аларнын уникесендә репродуктив система патологиясе ачыкланды. Шул исәптән 5 яшvсмердә беренче тапкыр авырулар ачыкланды.

Торбеево районындагы дәвалану һәм тикшеренv учреждениеларында дәвалануга мохтажларнын барысы да медицина ярдәме ала. Узган елда олкәннәргә, диспансеризация кысаларында, 2825 кеше тикшеренv vтте. Икенче этапка каралганнарнын 610 яки 21,6% ы жибәрелгән, бу 2024 ел белән чагыштырганда 18% ка яки 500 кешегә кvбрәк.

Ел саен ЭКО методын кулланып, бала тапмауны дәвалау vтәлә. 2025 елда Торбеево районы хатын-кызлары очен мәжбvри медицина иминияте (ОМС) акчалары хисабына унике ЭКО циклы vткәрелде.

Моннан тыш, СВОнын барлык ветераннары да диспансеризация белән тулы кvләмдә колачланган. Диспансеризация кысаларында олкән буын кешеләре (60 плюс) медицина тикшерvе узды. Тикшерелгәннәрнен артуы авыруларны иртә ачыклауда һонәри чараларнын мотивациясен һәм остенлеген раслый.

Узган ел районыбызда 81 бала туды. Бvгенге кондә без системалы, ведомствоара эш моделен тозибез: анда халык сәламәтлеге топ остенлек булып тора. Барлык кызыксынган структураларнын vзара хез-мәттәшлеге нәтижәсендә без тотрык-лы унай демографик нәтижәләргә ирешербез дип ометләнәбез.

**Н.ХӘЛИЛ**